# Балалар бакчасы шартларына ияләшү чорын ничек җиңеләйтергә?



Балалар бакчасы. Татар теле. vk.com/balalarbakchacy

## Сабые балалар бакчасына йөри башлаган әти-әнигә берничә киңәш.

1. Балалар бакчасы хезмәткәрләре белән тыгыз элемтә булдырыгыз.
2. Баланы яңа шартларга аз-азлап ияләштерегез.
3. Баланы бакчада баштагы чорда 8 сәгатьтән артык тотмагыз.
4. Тәрбиячеләргә балага кагылышлы мөһим мәгълүматларны җиткерегез.
5. Өйдә тыныч атмосфера тудырыгыз. Балага карата игътибарлы һәм түземле булыгыз.
8. Тавышлы бәйрәмнәр оештырырга, кунакка йөрергә тырышмагыз. Бала белән тыныч уеннар уйнагыз, күбрәк бергә булыгыз.

**«Тәрбияче-педагоглар, бала, әти-әни – бердәм команда» дигән фикергә өстенлек бирелсә иде.**



Балалар бакчасына йөри башлау – бала һәм әти-әни өчен зур сынау чоры. «Бакчада нарасыемны ни көтә, яңа кешеләргә ничек ияләшер, тәрбиячеләре нинди булыр?..» Мондый сораулар кемне генә борчымый икән?! Бу уйланулар урынлы да бит, чөнки 4–5 ел дәверендә сабыйның үсеше, тәрбиясе, сәламәтлеге, кичерешләре балалар бакчасы тормышы белән берлектә үрелеп барачак. Шуңа күрә бу чорга тәрбиячеләрнең һәм әти-әниләрнең җидти караулары мөһим. Баланың яңа шартларга уңышлы ияләшүе иң беренче чиратта ата-аналардан тора. Аларның балалар бакчасына карашы уңай булган очракта гына үзара уртак тел табу мөмкин булачак. Кайбер өлкәннәр балалар бакчасына, тәрбиячеләргә шик һәм курку белән карый, ә сабый эчке тоемлау сәләте белән моны сизә. Андый әти-әниләргә, кәгазь бите алып, баланы бакчага бирүнең уңай һәм тискәре якларын язып чыгарга киңәш ителә. Әгәр дә көтелгән нәтиҗәләрдә тискәре җаваплар күп икән, балалар бакчасына йөри башларга иртәрәк, дип нәтиҗә ясарга була. Шулай да, бу өлкәдә тәҗрибәсе булган әти-әниләр, гаилә әгъзалары белән тагын бер кат киңәшләшеп, уртак фикергә килергә кирәк. «Сабыйның үсешенә балалар бакчасы уңай нәтиҗә бирәчәк», – дип уйланылган очракта гына мәсьәләне уңай хәл итәргә була.

**Өлкәннәрнең бурычы – баланың бакчага ияләшү чорын җиңеләйтү һәм аңа тиешле психологик ярдәм күрсәтү. Түбәндәге киңәшләргә яшь әти-әниләр аеруча игътибарлы булса иде.**

**1. Баланы яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән ешрак аралаштыру мөһим. Башка балалар һәм аларның әти-әниләренә игътибарны юнәлтү, алар турында уңай фикер әйтү, бергә уйнарга, аралашырга өндәү уңай нәтиҗә бирәчәк.**

**2. Башка балалар белән уенчыкларны бүлешергә, дус-тату уйнарга, елаган балага ярдәм кулы сузарга, кирәк чакта үзенә дә ярдәм итүләрен сорый белергә өйрәтергә кирәк. Башкарган яхшы гамәле, нәтиҗәле эше, мөстәкыйльлеге өчен баланы һәрвакыт мактагыз, күңелен үстерегез.**

**3. Таныш булмаган бина, ят кешеләр балада курку хисе уятырга мөмкин. Бала тиздән бакчага барачагы, анда «чит» апалар, башка төрле уенчыклар булачагы турында хәбәрдар булырга тиеш. Балалар бакчасына кагылышлы уңай мәгълүматлар, шулай ук балага ошап бетмәскә мөмкин очраклар турында да (мәсәлән, балалар күп булу сәбәпле, аңа игътибарның җитеп бетмәү ихтималы, бакчада катгый кагыйдәләр булуы һ.б. турында) әңгәмә корылса яхшы.**



4. Сабыйны балалар бакчасына бирү процессын аны кызгану, уфтану кебек хисләр белән бәйләмәү мөһим. Әти-әнинең нарасыйны үз кочагыннан аерып җибәрергә әзер булмавы – аның балалар бакчасына уңышлы ияләшүенә комачаулый торган зур киртә.

5. Гаилә әгъзалары белән «Балалар бакчасы» уены уйнау балада бакчага карата җылы мөнәсәбәт тәрбияләп кенә калмый, аны көндәлек режим белән дә таныштыра.

6. Туганнарыгыз, танышларыгыз янында балагызның бакчага йөри башлавы, зур үсүе турында әйтсәгез, балада горурлык хисе уяныр, ул моның мөһим, кирәкле гамәл булуын тизрәк аңлар.

7. Бала белән ул барасы балалар бакчасы тирәсенә «сәяхәт» тә уңай нәтиҗә бирәчәк. Таныш бина балада ышаныч уятачак.

8. Балалар бакчасының көн тәртибе белән танышып, баланы шул режимга көйләсәгез, аңа яңа шартларга ияләшү бермә-бер җиңелрәк булачак.



**Балалар бакчасына ияләшүнең барышы берничә факторга бәйле. Болар – баланың:**

- яше;
- сәламәтлек торышы;
  акыл һәм психологик үсеш дәрәҗәсе;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралаша белүе;
- үен эшчәнлегенең формалашкан булуы;
- өйдәге көн тәртибенең балалар бакчасындагы режим белән якынча бертөрле булуы.



**Балалар бакчасына йөри башлаганчы, сабыйда ким дигәндә түбәндәге күнекмәләр формалашкан булырга тиеш:**

- урындыкка мөстәкыйль утыра белү;
- чокырдан мөстәкыйль эчә белү;
- кашык тотып ашый белү;
- аны киендергәндә һәм чишендергәндә актив катнашуы;
- чүлмәккә утыртуны сорый белмәсә дә, аның белән таныш булуы, утыртканда курыкмавы.

Балалар бакчасына сабый акрынлык белән ияләшергә тиеш. Әти-әнисенең аны озакка калдырып китүе кайбер балада курку хисе уята, яңадан килү теләген сүндерә. Шуны да истән чыгармаска кирәк: һәр баланың үз үзенчәлекләре бар. Берәүләре, китергәндә еламаса да, кич белән өйләренә кайткач елый; икенчеләре, иртә белән бакчага барырга риза булсалар да, килеп җиткәч, көйсезләнә башлыйлар. Әйткәнебезчә, баланың бакчага ияләшүе аның психик һәм физик халәтенә бәйле.

